**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 елның 4 сентябре №253

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу һәм алып бару буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә аерым вәкаләтләрен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Карамалы шәһәр җирлеге Советы **карар итте:**

1. «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу һәм алып бару буенча вәкаләтләрен тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең үз матди ресурслары һәм финанс чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче Май ур., 70нчы йорт җирлек административ бинасы).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Карамалы Тау шәһәр җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Җирлек башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Ю.М. Некрасова**